

Үткән атнада Мордовия Дәүләт Жыены рәисе Владимир Чибиркин Мордовиянен конбатыш районнарында эшлекле очрашулар vткәрде.
Ул Ельник районы башлыгы Юрий Бекешев белән бергә Краснослободск vзәк район хастаханәсе поликлиникасында булды. Анда сәламәтлек саклаунын беренчел звеносын модернизацияләv программасы буенча капиталь ремонт актив бара. Бу яна бина булачак; сvтелгәннән сон стеналар гына калган. Хәзер тvбә тозелә, аннан сон барлык коммуникацияләрне vткәрv, эчке бизәv һәм территорияне тозекләндерv эшләре башкарылачак. Эшләр графиктан алдарак бара.      “Әйтеп кирәргә кирәк, поликлиниканы ремонтлау – Ельник районы халкынын боерыгы. Объектта тәжрибәле тозvчеләр эшли. Проект ике елга исәпләнгән булса да, финанслауны тәэмин иткәндә, ремонтны вакытыннан алда башкарырга жыеналар. Бу мәсьәләне республика Хокvмәте белән хәл итәчәкбез. Монда сыйфатлы һәм арзан медицина ярдәме кvрсәтv очен кирәк булганнын барысын да эшләргә тиеш», – диде Мордовия Дәүләт Жыелышы рәисе Владимир Чибиркин.
Тагы Мордовия Дәүләт Жыелышы рәисе Владимир Чибиркин Краснослободск районында “Имин сыйфатлы юллар” милли проектынын vтәлеше белән танышты. Тозелеш объектларынын берсе - 6,5 км озынлыктагы Яна Карьга авылына юл тозекләндерv. Монда юл япмасын кинәйтv, су агызу урыннары урнаштыру планлаштырыла.
Район башлыгы Алексей Буйнов белән Владимир Чибиркин эшләрнен ничек баруын карап чыкты. Һава торышы аркасында алар вакытыннан алда башланган һәм яна уку елы башында ук тәмамланырга момкин. Бу укучыларны жирле мәктәпкә дәресләргә алып баруның куркынычсызлыгын һәм унайлылыгын арттырачак.
“Юл моһим, шул исәптән авылнын социаль-икътисади vсеше ягыннан да. Яна Карьгада авыл хужалыгы предприятиесе унышлы эшли, ул торак тозелеше хисабына яшь белгечләрне жәлеп итә. Аны жирле Совет депутаты Дмитрий Харитонов житәкли. Янартылган юл кадрлар житештерv һәм ныгыту очен остәмә момкинлекләр бирәчәк. Яна Карьга халкы ремонтны коткән. Эшләр югары сыйфатлы башкарылырга тиеш”, - диде Мордовия Дәүләт Жыелышы рәисе.
Чираттагы объект - Краснослободск районындагы “Алтын башак” (“Золотой колос”) сәламәтләндерv лагеры шактый янартылачак: шуны карау. Хәзерге вакытта инде эшләп килvче корпусларга остәп, һәркайсы 49 урынга исәпләнгән ике капиталь булмаган корпус тозелә.
Проект федераль субсидияләр жәлеп итv хисабына тормышка ашырыла, ял итv очен момкин кадәр унайлы шартлар тудырырга момкинлек бирәчәк: балалар барлык унайлыклары булган бvлмәләрдә ял итәчәкләр. Газ белән жылыту жәйге сменаларны гына тvгел, ә кышкы сменаларны да vткәрергә момкинлек бирәчәк.
Эшләр барышы белән Владимир Чибиркин таныштты. Подрядчы оешма житәкчесе Николай Шепелев конструкцияләрне монтажлау график буенча бара дип раслады. Объектларны май аенда, сәламәтләндерv кампаниясе башлануга тапшырылыр. Шулай ук

территория тозеклəндерелəчəк.
Район башлыгы Алексей Буйнов һəм район мəгариф идарəсе начальнигы Юлия Нотина белəн Владимир Чибиркин лагерьны əзерлəvнен агымдагы мəсьəлəлəрен тикшерде. Ул сменасына 200гə кадəр баланы кабул итə алачак.
“Проект “Балачак унъеллыгы” Президент программасы кысаларында тормышка ашырыла. Мордовия башлыгы Артём Алексеевич Здунов бу мəсьəлəгə зур игътибар бирə. Узган ел балалар лагере территориясендə тиз тозелə торган корпуслар Рузаевка районында тозеклəндерелде. Шуна кvрə хəзер “Алтын башак” та эшлəvче белгечлəрнен инде кирəкле тəжрибəсе бар. Безнен бурыч – балалар очен унайлы ял итv шартлары тудыру”, - диде Владимир Чибиркин.

**Наилə НАСЫРОВА**